**2024-2025 уку елы**
**Интернет тур.**

**10-11 нче сыйныфлар**
**1 нче вариант**
**А тибындагы биремнәр барысы да 4 балл белән, В тибындагы биремнәр барысы да 6 балл белән бәяләнә.**

**А1. Дөрес язылмаган сүзне билгеләгез. (4 балл)**
1) төтен
2) поши
3) болыт
**4) сөлгө**

**А2. Ачык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. (4 балл)**
**1) тәрәзә**
2) ишек
3) түшәм
4) дивар

**А3.** ***Баланың телен анасы белер.*** **(Мәкаль) җөмләсендәге саңгырау тартыкларның санын билгеләгез. (4 балл)**
1) 1
**2) 2**
3) 3
4) 4

**А4. Бер мәгънәгә генә ия булган сүзне билгеләгез. (4 балл)**
1) баш
2) итәк
**3) шәл**
4) алтын

**А5.** ***Куцат*** **диалекталь сүзенең әдәби телдәге вариантын билгеләгез. (4 балл)**
1) курчак
**2) әтәч**
3) тавык
4) көчек

**А6.** ***Борынга чиртү*** **фразеологик әйтелмәсенең мәгънәсен билгеләгез. (4 балл)**

**1) узып китү, җиңү**

2) кыйнау, сугу

3) күңелсезләнү

4) кызыгып йөрү

**А7. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. (4 балл)**

1) бал, балчык

2) бал, балык

3) су, суыткыч

**4) су, сулык**

**А8. Чикләүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. (4 балл)**

1) дөм

**2) гына**

3) ич

4) -дыр

**А9.** ***Кеше яраткан эшен яхшы эшли.*** **(Мәкаль) җөмләсендәге** ***яраткан*** **сүзенең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. (4 балл)**

1) хәбәр

2) рәвеш хәле

3) сәбәп хәле

**4) аергыч**

**А10.** ***Ил аткан таш ерак китә.*** **(Мәкаль) җөмләсенең төрен билгеләгез. (4 балл)**

1) гади җөмлә

2) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

3) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

**4) иярченле кушма җөмлә**

**В1. [м], [н], [л], [р], [й], [ң], [w] – ... яңгырау тартыклар. (6 балл)**

**Җавап (Ответ): ПАРСЫЗ**

**В2.** **…** ***чабып көлү*** **фразеологик әйтелмәсенең төшеп калган сүзен языгыз. (6 балл)**

**Җавап (Ответ): БОТ**

**В3.** ***Зонтик*** **сүзенең татарча тәрҗемәсен языгыз. (6 балл)**

**Җавап (Ответ): КУЛЧАТЫР**

**В4. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (6 балл)**

| | |
|---|---|
| А) урманнар | 1) ирен ассимиляциясе күзәтелә |
| Б) китаптан | 2) борын ассимиляциясе күзәтелә |
| В) унбер | 3) тел арты ассимиляциясе күзәтелә |
| Г) әнкәй | 4) саңгыраулыкта охшашлану күзәтелә |

**Җавап (Ответ): 2413**

**В5. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (6 балл)**

| | |
|---|---|
| А) күлмәк | 1) кушма сүз |
| Б) ташкабак | 2) парлы сүз |
| В) татфак | 3) тамыр сүз |
| Г) ир-ат | 4) кыскартылма сүз |

**Җавап (Ответ): 3142**

**В6.** ***Бирәүнең буе КЫСКА, бирәүнең уе кыска.*** **(Мәкаль) җөмләсендә аерып бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый? (6 балл)**

**Җавап (Ответ): СЫЙФАТ**

**В7.** ***Кырга барганда мактанма, кайтканда мактан.*** **(Мәкаль) җөмләсендә нинди җөмлә кисәкләре тиңдәшләнеп килгән? (6 балл)**

**Җавап (Ответ): ХӘБӘРЛӘР**

**В8.** ***Язгы хезмәт <...> көзге хөрмәт.*** **(Мәкаль) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (6 балл)**
**Җавап (Ответ): СЫЗЫК**

**B9. Тексттан тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (6 балл)**

1) Чәй эчкәч, без өчебез дә бакчага чыктык. 2) Әнием тимер көрәк алды. 3) Оксана белән миңа кечкенә тимер тырманы тоттырды. 4) Ул, көрәген батыра-батыра, җирне казый башлый. 5) Агачны утырту өчен, башта чокыр ясарга кирәк шул. 6) Кичә Мансур бабай да шулай итте. 7) Ул да ике алмагач, дүрт чия агачы утыртты. 8) Үзе гел нидер сөйли. 9) «Бу агачларның җимешләрен мин күрә алмам инде, балалар. 10) Ә сез үсеп җитүгә аларның җимешләре өлгерер. 11) Мин күрмәсәм, сез күрерсез. 12) Мин шуңа риза...». 13) Бабай билен уа-уа чак кына басып торды да тагын сөйли башлый. 14) «Дөньяда кеше үзе өчен генә яшәргә тиеш түгел. 15) Әнә, күктә йөзгән кояшны карагыз, ул бөтен җирне җылыта...».

16) Без, кулларыбызны каш өстенә куеп, күккә карыйбыз. 17) Баш өстендә, зур күк түбәсендә, кечкенә кояш тора. 18) Ул үзе эссе, үзе якты. (М. Кәримнән)

**Җавап (Ответ): 3713**

**B10. Тексттан иярченле кушма җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (6 балл)**

1) Чәй эчкәч, без өчебез дә бакчага чыктык. 2) Әнием тимер көрәк алды. 3) Оксана белән миңа кечкенә тимер тырманы тоттырды. 4) Ул, көрәген батыра-батыра, җирне казый башлый. 5) Агачны утырту өчен, башта чокыр ясарга кирәк шул. 6) Кичә Мансур бабай да шулай итте. 7) Ул да ике алмагач, дүрт чия агачы утыртты. 8) Үзе гел нидер сөйли. 9) «Бу агачларның җимешләрен мин күрә алмам инде, балалар. 10) Ә сез үсеп җитүгә аларның җимешләре өлгерер. 11) Мин күрмәсәм, сез күрерсез. 12) Мин шуңа риза...». 13) Бабай билен уа-уа чак кына басып торды да тагын сөйли башлый. 14) «Дөньяда кеше үзе өчен генә яшәргә тиеш түгел. 15) Әнә, күктә йөзгән кояшны карагыз, ул бөтен җирне җылыта...».

16) Без, кулларыбызны каш өстенә куеп, күккә карыйбыз. 17) Баш өстендә, зур күк түбәсендә, кечкенә кояш тора. 18) Ул үзе эссе, үзе якты. (М. Кәримнән)

**Җавап (Ответ): 1011**

**10-11 нче сыйныфлар**
**2 нче вариант**

**А1. Дөрес язылмаган сүзне билгеләгез. (4 балл)**
1) бөтен
2) кошчык
3) болын
**4) көзгө**

**А2. Ачык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. (4 балл)**
**1) бүре**
2) куян
3) төлке
4) керпе

**А3. *Бер тамчыдан диңгез булмый.* (Мәкаль) җөмләсендәге саңгырау тартыкларның санын билгеләгез. (4 балл)**
1) 1
**2) 2**
3) 3
4) 4

**А4. Бер мәгънәгә генә ия булган сүзне билгеләгез. (4 балл)**
1) койрык
2) аяк
**3) кулъяулык**
4) тел

**А5. *Айбагар* диалекталь сүзенең әдәби телдәге вариантын билгеләгез. (4 балл)**
1) йолдыз
**2) көнбагыш**
3) кояш
4) авыл

**А6. *Борын салындыру* фразеологик әйтелмәсенең мәгънәсен билгеләгез. (4 балл)**
**1) күңелсезләнү**
2) мактану
3) горурлану
4) аптырау

**А7. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. (4 балл)**

1) ел, елга
2) ел, елан
3) бил, билге
**4) бит, битлек**

**А8. Чикләүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. (4 балл)**
1) сап-
**2) кына**
3) -чы
4) түгел

**А9. *Калган эшкә кар ява.* (Мәкаль) җөмләсендәге *калган* сүзенең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. (4 балл)**
1) хәбәр
2) рәвеш хәле
3) сәбәп хәле
**4) аергыч**

**А10. *Ил белән этәргәч, тау күчкән.* (Мәкаль) җөмләсенең төрен билгеләгез. (4 балл)**
1) гади җөмлә
2) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
3) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
**4) иярченле кушма җөмлә**

**В1. [ц], [щ], [х], [һ] – ... саңгырау тартыклар. (6 балл)**

**Җавап (Ответ): ПАРСЫЗ**

**В2. … *төкереп яту* фразеологик әйтелмәсенең төшеп калган сүзен языгыз. (6 балл)**

**Җавап (Ответ): ТҮШӘМГӘ**

**В3. *Холодильник* сүзенең татарча тәрҗемәсен языгыз. (6 балл)**

**Җавап (Ответ): СУЫТКЫЧ**

**В4. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (6 балл)**

| | |
|---|---|
| А) болыннар | 1) ирен ассимиляциясе күзәтелә |
| Б) мәктәптән | 2) борын ассимиляциясе күзәтелә |
| В) көнбагыш | 3) тел арты ассимиляциясе күзәтелә |
| Г) көнгерә | 4) саңгыраулыкта охшашлану күзәтелә |

**Җавап (Ответ): 2413**

**В5. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. (6 балл)**

| | |
|---|---|
| А) чүлмәк | 1) кушма сүз |
| Б) гөлҗимеш | 2) парлы сүз |
| В) журфак | 3) тамыр сүз |
| Г) мал-туар | 4) кыскартылма сүз |

**Җавап (Ответ): 3142**

**В6. *Кеше кулындагы калач ЗУР күренә.* (Мәкаль) җөмләсендә аерып бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый? (6 балл)**

**Җавап (Ответ): СЫЙФАТ**

**В7. *Теләмә озын җәй, телә яхшы җәй.* (Мәкаль) җөмләсендә нинди җөмлә кисәкләре тиңдәшләнеп килгән? (6 балл)**

**Җавап (Ответ): ХӘБӘРЛӘР**

**В8. *Тел <...> күңелнең көзгесе.* (Мәкаль) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. (6 балл)**
**Җавап (Ответ): СЫЗЫК**

**В9. Тексттан тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (6 балл)**

1) Ундүрт-унбиш яшьлек чагымда җәен дә, кышын да мин суга барырга ярата идем. 2) Шул су юлы кыш көне тар гына сукмак булып кала. 3) Салкын һава битләрне кызарта... 4) Әниемнең зәңгәр шәле бар иде. 5) Менә шул шәлне башыма бәйләп, яңакларны, бит алмаларын мөмкин кадәр шәл астына яшереп, зәңгәр көянтәмә чиләкләр асам да әкрен генә могҗиза иленә таба атлыйм. 6) Көн кояшлы булса, кар көртләре меңләгән-миллионлаган йолдызчыкларга әверелеп җемелдәшәләр. 7) Табигать юлыма, тирә-ягыма энҗе-мәрҗәннәр сибә кебек. 8) Аларның яктысына түзә алмыйча, күзләрем яшьләнә, дөнья тоташ аклыкка, яктылыкка күмелә. 9) Болытлы көнне, гадәттә, кар көртләре өстеннән җил шуышып уза. 10) Ул я йөзгә кытыршы кар бөртекләре белән бәрә, я алга таба этә, адымнарны тизләтә...

11) ...Әнә шул салкын җилне дә сагынам. 12) Бу кайтуда әниемнән көянтәләр сорадым. 13) Башта әнием бик гаҗәпләнде, көлеп, аркамнан сөйде: хәзер көянтә белән су ташымыйлар икән инде. (Х. Ширмәннән)

**Җавап (Ответ): 15781013**

**B10. Тексттан иярченле кушма җөмләләрне табыгыз һәм аларның санын арта бару тәртибендә күрсәтегез. (6 балл)**

1) Ундүрт-унбиш яшьлек чагымда җәен дә, кышын да мин суга барырга ярата идем. 2) Шул су юлы кыш көне тар гына сукмак булып кала. 3) Салкын һава битләрне кызарта... 4) Әниемнең зәңгәр шәле бар иде. 5) Менә шул шәлне башыма бәйләп, яңакларны, бит алмаларын мөмкин кадәр шәл астына яшереп, зәңгәр көянтәмә чиләкләр асам да әкрен генә могҗиза иленә таба атлыйм. 6) Көн кояшлы булса, кар көртләре меңләгән-миллионлаган йолдызчыкларга әверелеп җемелдәшәләр. 7) Табигать юлыма, тирә-ягыма энҗе-мәрҗәннәр сибә кебек. 8) Аларның яктысына түзә алмыйча, күзләрем яшьләнә, дөнья тоташ аклыкка, яктылыкка күмелә. 9) Болытлы көнне, гадәттә, кар көртләре өстеннән җил шуышып уза. 10) Ул я йөзгә кытыршы кар бөртекләре белән бәрә, я алга таба этә, адымнарны тизләтә...

11) ...Әнә шул салкын җилне дә сагынам. 12) Бу кайтуда әниемнән көянтәләр сорадым. 13) Башта әнием бик гаҗәпләнде, көлеп, аркамнан сөйде: хәзер көянтә белән су ташымыйлар икән инде. (Х. Ширмәннән)

**Җавап (Ответ): 613**